Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге
Югары Әлморза авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2019 елның 29 ноябре

2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 18 номерлы Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, , «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 10 октябрендәге 16 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе» турындагы карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлегенең Югары Әлморза авылында 2019 елның 29 ноябрендәге 3 номерлы гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге составына керүче Югары Әлморза авылындагы гражданнар җыены үткәрелгән, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Юхмачы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
алардан:

- урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтү һәм урам утларын кулланган энергиягә чыгымнарны түләүгә-170 сум;

- су башнялары территорияләрен койма белән әйләндереп алу, ызанлау, проектлау, төзү, реконструкцияләү, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләүгә бәйле чыгымнарга – 150 сум;

- авыл эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү, төзекләндерү, ягулык-майлау материаллары, авыл җирлеге тракторына запас частьләр алу белән бәйле чыгымнарга -180 сум.;

– каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерүгә һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнарга-100 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

**3.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Юхмачы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
алардан:
- урамнарны яктыртуга кирәкле материал сатып алу, яктырту җиһазлары урнаштыру буенча электромонтаж эшләре, хезмәт күрсәтү һәм урам утларын кулланган энергиягә чыгымнарны түләүгә-170 сум;
- су башнялары территорияләрен койма белән әйләндереп алу, ызанлау, проектлау, төзү, реконструкцияләү, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм су лаборатор-инструменталь тикшеренүләр өчен түләүгә бәйле чыгымнарга – 150 сум;
- авыл эчендәге юлларга хезмәт күрсәтү, төзекләндерү, ягулык-майлау материаллары, авыл җирлеге тракторына запас частьләр алу белән бәйле чыгымнарга -180 сум.;
– каты көнкүреш калдыклары өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алуга бәйле чыгымнарга-100 сум.

4.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Юхмачы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Юхмачы авыл җирлеге башлыгы: Р. Ә. Сәлахов